**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2079**
**20.04.2022**

Яр Чаллы шәһәренең «Мәдәният һәм ял паркы» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 пунктның 4 пунктчасына, шәһәр Уставының 41 статьясына, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакындагы нигезләмәнең 5 пунктына, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәгә туры китереп

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Мәдәният һәм ял паркы» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитет карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Яр Чаллы шәһәренең «Мәдәният һәм ял паркы» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2018 елның 9 апрелендәге1931 номерлы;

2) «Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Мәдәният һәм ял паркы» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2018 елның 9 апрелендәге 1931 номерлы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 10 июнендәге 2955 номерлы.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 20 апрелендәге
2079 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «Мәдәният һәм ял паркы» МУП
тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге (бер сеанс) | Чик тариф сумнарда |
|---|---|---|---|
| Балалар аттракционнары | | | |
| 1 | Карнавал | 3 мин | 50 |
| 2 | Кыңгырау | 3 мин | 50 |
| 3 | Юнга | 3 мин | 50 |
| 4 | Рельстагы джип | 3 мин | 50 |
| 5 | «Мультфильм геройлары» мультпоезды | 3 мин | 70 |
| 6 | «Миниаэропорт» каруселе | 3 мин | 60 |
| 7 | Кояшкай | 3 мин | 50 |
| 8 | «Җилкәй» балалар чылбыры | 3 мин | 70 |
| 9 | Җиләк-җимешләр | 3 мин | 100 |
| 10 | Батутлар (10 минут) | 10 мин | 100 |
| 11 | Күңелле утыргыч | 3 мин | 100 |
| 12 | Индеецлар елгасы | 5 мин | 70 |
| 13 | Мини-джет | 3 мин | 60 |
| 14 | «Аквазорб» су шарлары | 5 мин | 150 |
| Гаилә аттракционнары | | | |
| 15 | Көлке бүлмәсе | 3 мин | 20 |
| 16 | Тир (5 тапкыр ату) | 3 мин | 50 |
| 17 | Экспресс-Шоссе (кечкенә паровоз) | 10 мин | 70 |
| 18 | Экспресс-Шоссе (зур паровоз) | 10 мин | 70 |
| 19 | Орбита | 3 мин | 100 |
| 20 | Күңелле таулар | 3 мин | 120 |
| 21 | «Сафари» тиры | 3 мин | 70 |
| 22 | Автодром (1 машина) | 3 мин | 150 |
| 23 | Судагы көймәләр (1 көймә) | 5 мин | 150 |
| 24 | Күзәтү тәгәрмәче 40 м | 7 мин | 150 |
| 25 | Бильярд (1 өстәл) | 30 мин | 100 |
| 26 | Өстәл теннисы (1 өстәл) | 30 мин | 100 |
| 27 | Гусеница | 4 мин | 70 |
| 28 | Аккошлар (1 кабина) | 3 мин | 150 |
| 29 | Виртуаль (4D фильмнар) | 7 мин | 100 |
| 30 | Туй каруселе | 3 мин | 100 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 31 | «ФутуРифт» виртуаль чынбарлык | 5 мин | 150 |
| Экстремаль аттракционнар | | | |
| 32 | Өермә | 3 мин | 100 |
| 33 | Сюрприз | 3 мин | 70 |
| 34 | Вальс | 3 мин | 150 |
| 35 | Астронавт | 3 мин | 150 |
| 36 | Оча торган тәлинкә | 3 мин | 150 |
| 37 | Зодиак | 3 мин | 150 |
| 38 | Оча торган голландияле | 3 мин | 150 |
| 39 | Стелла-Магнетик | 3 мин | 150 |
| 40 | Хип-Хоп | 3 мин | 150 |
| 41 | Биоробот | 3 мин | 150 |
| 42 | Диңгездә ау | 3 мин | 150 |
| 43 | Чылбырлы карусель | 9 мин | 150 |
| | | | |
| 44 | Чаңгылар | 1 сәгать | 150 |
| 45 | Тимераяклар | 1 сәгать | 150 |
| 46 | Тюбинглар | 1 сәгать | 150 |
| 47 | Бәдрәф | 3 мин | 10 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева